# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 5 өлешендәге сигезенче абзацында "муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфалары" сүзләрен "муниципаль хезмәт вазыйфалары" сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Дәүләт хезмәтенең класслы чиннары**

1. Дәүләт хезмәткәрләренә дәүләт хезмәте вазыйфасы төркемнәренә туры килә торган дәүләт хезмәтенең түбәндәге класслы чиннары (алга таба шулай ук – класслы чиннар) бирелә:

1) иң югары төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе;

2) баш төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе;

3) әйдәүче төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе;

4) өлкән төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты;

5) кече төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре.

2. Классны чин беренче яисә чираттагысы булырга мөмкин.

3. Беренче классны чиннар дип (дәүләт хезмәткәре биләүче дәүләт хезмәте вазыйфасы керә торган дәүләт хезмәте вазыйфалары төркеменә бәйле рәвештә) 3 классны вазыйфаларның тиешле төркеме буенча классны чиннар санала.";

3) түбәндәге эчтәлекле $11^1 – 11^4$ статьялар өстәргә:

"$11^1$ статья. **Дәүләт хезмәтен классны чиннарда узу сроклары**

1. Дәүләт хезмәтен узу өчен классны чиннарда булуның түбәндәге сроклары билгеләнә:

3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре – кимендә бер ел;

2 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре – кимендә бер ел;

3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты – кимендә бер ел;

2 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты– кимендә бер ел;

3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе – кимендә ике ел;

2 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе – кимендә ике ел;

3 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе – кимендә ике ел;

2 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе – кимендә ике ел;

3 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе – кимендә бер ел;

2 классл Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе – кимендә бер ел.

2. 1 классл Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре, 1 классл Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты, 1 классл Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе, 1 классл Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе классл чиннарында булуның минималь сроклары билгеләнми.

3. Бирелгән классл чинда булу срогы классл чин биргән көннән исәпләнә.

4. Классл чин биргән көн дип дәүләт хезмәткәре тарафыннан квалификация имтиханы бирелгән көн санала. Квалификация имтиханы уздырмыйча гына классл чин бирүнең әлеге Закон белән билгеләнгән очракларында классл чин бирү көне дип классл чин бирү турында карар кабул ителгән көн санала.

### $11^2$ статья. **Дәүләт хезмәтенең классл чиннарын бирү тәртибе**

1. Классл чиннар дәүләт хезмәткәрләренә, эзлеклелекне үтәгән килеш, дәүләт хезмәте вазыйфалары төркеме чикләрендә биләнә торган вазыйфасы нигезендә, шулай ук профессиональ дәрәҗәсен, элеккеге классл чинда һәм биләнә торган дәүләт хезмәте вазыйфасында дәүләт хезмәтенең дәвамлылыгын исәпкә алып, шәхсән бирелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең классл чины булмаган дәүләт хезмәткәренә ул били торган вазыйфасы керүче дәүләт хезмәте вазыйфасы төркеме өчен беренче булган классл чин бирелә.

3. Беренче классл чин дәүләт хезмәткәренә сынавын уңышлы тәмамлаганнан соң, ә сынау билгеләнмәгән булса, дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләгәннән соң өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта бирелә.

4. Чираттагы классл чин дәүләт хезмәткәренә элеккеге классл чинда дәүләт хезмәте узу өчен билгеләнгән минималь срок узгач һәм ул дәүләт хезмәткәренә бирелә торган классл чинга тиң яисә аннан югарырак классл чин каралган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү шарты белән бирелә.

5. "Белгечләр" һәм "тәэмин итүче белгечләр" категорияләренең дәүләт хезмәте вазыйфаларын, шулай ук дәүләт хезмәтенең баш һәм әйдәүче төркемнәренә керә торган "җитәкчеләр" категориясенең дәүләт хезмәте вазыйфаларын вәкаләтләре срогы чикләнмичә генә биләүче дәүләт хезмәткәрләренә классл чиннар алар квалификация имтиханын биргәннән соң бирелә.

6. Дәүләт хезмәтенең иң югары төркеменә керә торган "җитәкчеләр" категориясенең дәүләт хезмәте вазыйфасын вәкаләтләре срогы чикләнмичә генә

биләүче дәүләт хезмәткәрләренә классны чиннар, шушы хезмәткәрләр тарафыннан квалификация имтиханын бирү турындагы карар дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән булса, алар квалификация имтиханын биргәннән соң бирелә.

7. Дәүләт хезмәтенең классны чиннары – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органнары җитәкчеләре тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан бирелә.

8. Дәүләт хезмәтенең классны чиннары – 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе түбәндәгеләргә бирелә:

1) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан бирелә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан бирелә;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә – тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бирелә;

4) Татарстан Республикасының бүтән дәүләт органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә – Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан бирелә.

9. 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе, 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты, 1, 2 яисә 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре классны чиннары дәүләт хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан бирелә.

10. Әлеге статья максатлары өчен Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе дигәндә Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат йә шушы җитәкченең яисә затның Татарстан Республикасы дәүләт органының хокукый акты нигезендә Татарстан

Республикасының тиешле дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куюю вәкаләтләре тапшырылган вәкиле аңлашыла.

11. Дәүләт хезмәткәренә классны чин бирү турындагы карар тиешенчә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органы җитәкчесе акты белән рәсмиләштерелә.

12. Классны чин бирү турындагы язма дәүләт хезмәткәренең шәхси эшнамәсенә һәм хезмәт кенәгәсенә кертелә.

13. Дәүләт хезмәткәрен вазыйфаларның элеккеге төркеме чикләрендә дәүләт хезмәтенең югарырак вазыйфасына билгеләп куйганда, әгәр аның элеккеге классны чинда булуының әлеге Законның $11^1$ статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән срогы узган булса, аңа чираттагы классны чин бирелә.

14. Дәүләт хезмәткәрен ул элегрәк биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасының югарырак төркеменә керә торган дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда шушы хезмәткәргә, әгәр бу классны чин дәүләт хезмәткәренең классны чиныннан югарырак булса, әлеге Законның 11 статьясындагы 3 өлеше нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфаларының шушы төркеме өчен беренче булган классны чин бирелә. Әлеге очракта классны чин эзлеклелек үтәлмичә генә һәм элеккеге классны чинда булу срогын исәпкә алмыйча гына бирелә.

15. Дәүләт хезмәтендәге аерым казанышлары өчен бүләкләү чарасы буларак дәүләт хезмәткәренә чираттагы классны чин түбәндәгечә бирелергә мөмкин:

1) дәүләт хезмәте вазыйфаларының биләнүче вазыйфасы керә торган төркеме чикләрендә вакытыннан алда (тиешле классны чинда дәүләт хезмәте узу өчен әлеге Законның $11^1$ статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән срок үткәнче):

а) 2 классны – 3 классны чины булган дәүләт хезмәткәренә, әмма 3 классны чин бирелгән көннән соң алты ай узгач кына;

б) 1 классны – 2 классны чины булган дәүләт хезмәткәренә, әмма 2 классны чин бирелгән көннән соң алты ай узгач кына;

2) дәүләт хезмәте вазыйфаларының биләнүче вазыйфасы керә торган төркеме чикләрендә чираттан тыш (классны чиннарның эзлеклелеген үтәмичә бер баскычка югарырак) – 1 классны – 3 классны чины булган дәүләт хезмәткәренә, әмма тиешле 3 классны чинда дәүләт хезмәте узу өчен әлеге Законның $11^1$ статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән срок узгач кына.

16. Чираттагы классны чин дисциплинар җәза бирелгән дәүләт хезмәткәрләренә, шулай ук үзләренә карата хезмәт тикшерүе алып барыла торган яисә җинаять җаваплылыгы кузгатылган дәүләт хезмәткәрләренә бирелми.

17. Дәүләт хезмәткәренә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 16 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, бер айдан да соң булмаган срокта кабул ителергә тиеш:

1) квалификация имтиханын уздырган көннән;

2) класслы чиннар бирергә вәкаләтле органга яисә вазыйфаи затка барлык кирәкле документлары белән бергә класслы чин бирү турында тәкъдим керткән көннән – квалификация имтиханыннан башка гына класслы чин һәм әлеге статьяның 7 өлешендә, шулай ук 8 өлешендәге 3 пунктында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында вазыйфалар биләүче дәүләт хезмәткәрләре өчен күрсәтелгән класслы чиннар биргәндә.

**$11^3$ статья. Федераль дәүләт граждан хезмәтенең класслы чины, дипломатик рангы, хәрби яисә махсус исеме, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең класслы чины яисә муниципаль хезмәткәрнең класслы чины булган гражданга класслы чин бирү**

1. Федераль дәүләт граждан хезмәтенең класслы чины, дипломатик рангы, хәрби яисә махсус исеме, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең класслы чины яисә муниципаль хезмәткәрнең класслы чины булган граждан дәүләт хезмәтенә кергәндә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенең беренче класслы чины дәүләт хезмәте вазыйфалары төркеме чикләрендә биләнә торган дәүләт хезмәте вазыйфасы нигезендә бирелә.

2. Әгәр, муниципаль хезмәт вазыйфаларының һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән нисбәтен исәпкә алып, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең класслы чины дәүләт хезмәткәренең муниципаль хезмәттәге класслы чиныннан түбәнрәк булса, дәүләт хезмәткәренә аның муниципаль хезмәттәге ул биләгән тиешле вазыйфадагы класслы чиныннан түбәнрәк булмаган, әмма дәүләт хезмәтенең биләнүче вазыйфасы керә торган вазыйфалар төркеме чикләрендә 1 классллы чиннан да югарырак булмаган класслы чин бирелә.

3. Әгәр, класслы чиннарның билгеләнгән нисбәтенең әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән класслы чин дәүләт хезмәткәренең федераль дәүләт граждан хезмәтендәге классллы чиныннан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус исеменнән, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең класслы чиныннан түбәнрәк булса, дәүләт хезмәткәренә ул били торган вазыйфага туры килерлек, аның федераль дәүләт граждан хезмәтендәге классллы

чиныннан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус исемennән, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтендәге класслы чиныннан түбәнрәк булмаган, әмма ул били торган вазыйфа кертелүче дәүләт вазыйфалары төркеме чикләрендә 1 классլы чиннан югарырак булмаган классլы чин бирелә.

4. Федераль дәүләт граждан хезмәтенең, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең классլы чины булган дәүләт хезмәткәренә әлеге Закон нигезендә классլы чин бирү максатлары өчен классլы чиннарның түбәндәге нисбәте билгеләнә:

1 классլы Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе – 1 классլы Россия Федерациясе хакыйкый дәүләт киңәшчесе, 1 классլы Россия Федерациясе субъектының хакыйкый дәүләт киңәшчесе;

2 классլы Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе – 2 классլы Россия Федерациясе хакыйкый дәүләт киңәшчесе, 2 классլы Россия Федерациясе субъектының хакыйкый дәүләт киңәшчесе;

3 классլы Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе – 3 классլы Россия Федерациясе хакыйкый дәүләт киңәшчесе, 3 классլы Россия Федерациясе субъектының хакыйкый дәүләт киңәшчесе;

1 классլы Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе – 1 классլы Россия Федерациясе дәүләт киңәшчесе, 1 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт киңәшчесе;

2 классլы Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе – 2 классլы Россия Федерациясе дәүләт киңәшчесе, 2 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт киңәшчесе;

3 классլы Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе – 3 классլы Россия Федерациясе дәүләт киңәшчесе, 3 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт киңәшчесе;

1 классլы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе – 1 классլы Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе, 1 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе;

2 классլы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе – 2 классլы Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе, 2 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе;

3 классլы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе – 3 классլы Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе, 3 классլы Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе;

1 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты – 1 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте референты, 1 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте референты;

2 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты – 2 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте референты, 2 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте референты;

3 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты – 3 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте референты, 3 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте референты;

1 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре – 1 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте секретаре, 1 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте секретаре;

2 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре – 2 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте секретаре, 2 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте секретаре;

3 классды Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре – 3 классды Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте секретаре, 3 классды Россия Федерациясе субъектының дәүләт граждан хезмәте секретаре.

5. Федераль дәүләт хезмәтенең башка төрендәге классды чины, дипломатик рангы булган дәүләт хезмәткәренә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенең классды чинын бирү федераль дәүләт граждан хезмәтенең классды чиннарының һәм хәрби һәм махсус исемнәрнең, хокук саклау хезмәтенең классды чиннарының федераль законнарда билгеләнгән нисбәте нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Чираттагы классды чин биргәндә федераль дәүләт граждан хезмәтенең классды чинында, дипломатик рангта, хәрби яисә махсус исемдә, Россия Федерациясенең башка субъектының дәүләт граждан хезмәтенең классды чинында яисә муниципаль хезмәткәрнең классды чинында булган вакыт исәпкә алына.

## $11^4$ статья. **Дәүләт хезмәтенең классды чинын саклап калу һәм аннан мәхрүм итү**

1. Бирелгән классды чин дәүләт хезмәткәрендә аны дәүләт хезмәтендәге биләгән вазыйфасыннан азат иткәндә һәм дәүләт хезмәтеннән җибәргәндә (шул исәптән пенсиягә чыкканда), шулай ук кабат дәүләт хезмәтенә урнашканда сакланып кала.

2. Дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләп куйганда аңа бирелгән классы чин билгеләнгән тәртиптә аңа чираттагы классы чин бирелгәнче сакланып кала.

3. Бирелгән классы чиннан мәхрүм итү федераль законнар нигезендә суд карары белән башкарылырга мөмкин.";

4) 31 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында "торак мәйданын" сүзләрен "торак урынын" сүзләренә алмаштырырга;

5) 32 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында "муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфалары" сүзләрен "муниципаль хезмәт вазыйфалары" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 70-ТРЗ